# Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Чуаш Киштәге авыл җирлеге составына керүче Новоселки торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре

14.11.2025 № 2

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Чуаш Киштәге авыл җирлегенең Новоселки авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – Новоселки авылында торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны вак таш белән салу), торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (юлларны кардан чистарту, эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү) өчен тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча 2025 елның 14 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны-66 кеше. Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 57 катнашучы кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 30 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашкан 30 кеше «әйе» позициясе өчен тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Буа муниципаль районы Чуаш Киштәге авыл җирлегенең Новоселки авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.

2. «Чуаш Киштәге авыл җирлегенең Новоселки авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – Новоселки авылында торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны вак таш белән салу), торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (юлларны кардан чистарту, эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү) өчен тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Буа муниципаль районының рәсми сайтында һәм Новоселки авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Чуаш Киштәге авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: ___________ И.А.Павлов

Чуаш Киштәге авыл җирлеге башлыгы __________________ И.А.Павлов